**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 2 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Игәнә-Баш авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Игәнә-Баш авылы эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш җәелгән чокырлар ремонтлау, вак таш ташу);
- Игәнә-Баш авылында «Беларус 82.1 " тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
- Игәнә-Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);
- Игәнә-Баш авылы зиратына инвентарь сатып алу;
- Игәнә-Баш авылы эчендәге юлларны кардан чистарту;
- янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар (мотопомпалар өчен запас частьләр) сатып алу;
- Игәнә-Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар, Җиңү көне, Өлкәннәр көне, Яңа ел) үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Әлеге карарны Илексаз авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Гыйлфанов Ф.М.